**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 2 май № 255

г. Казань

Татарстан Республикасы территориясендә гражданнар оборонасының саклагыч корылмаларын саклау һәм рациональ файдалану чаралары турында

«Гражданнар оборонасы турында» 1998 елның 12 февралендәге 28-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Саклагыч урыннар һәм гражданнар оборонасының бүтән объектларын төзү тәртибе турында» 1999 ел, 29 ноябрь, 1309 нчы һәм «Хосусыйлаштырылган предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар тарафыннан гражданнар оборонасы объектларыннан һәм мөлкәтеннән файдалану тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 1994 ел, 23 апрель, 359 нчы карарлары нигезендә, шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә гражданнар оборонасының саклагыч корылмалары фондын төзү, саклау, рациональ файдалану һәм билгеләнеше буенча файдалануга әзерлеген күтәрү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына эшләргә, шулай ук Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигать бәла-казалары нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенә тәкъдим итәргә:

гражданнар оборонасы объектларын төзүне һәм аларны файдалануга даими әзерлек хәлендә тотуны тикшерүдә тотуны гамәлгә ашырырга;

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы белән бергә:

гражданнар оборонасының саклагыч корылмалары фондын билгеләнеше буенча файдалануга әзерлекне күтәрүгә юнәлдерелгән чаралар үткәрүне оештырырга;

Татарстан Республикасы гражданнар оборонасы җитәкчесе – Татарстан Республикасы Премьер-министрының «Татарстан Республикасы гражданнар оборонасының саклагыч корылмаларын һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең запас идарә пунктларын иң яхшы карап тоту һәм әзерлек дәрәҗәсенә

смотр-конкурсы үткәрү турында» 2007 ел, 18 июнь, 9 нчы боерыгы нигезендә ел саен Татарстан Республикасы гражданнар оборонасының саклагыч корылмаларын иң яхшы карап тоту һәм билгеләнеше буенча файдалануга әзерлекнең торышына республика смотр-конкурсы үткәрүне оештырырга.

2. Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигать бәла-казалары нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенә тикшерүдә тоту һәм күзәтү чараларын планлаштырганда һәм гамәлгә ашырганда гражданнар оборонасының саклагыч корылмаларын карат тотуга аерым игътибар итүне тәкъдим итәргә.

3. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына тәкъдим итәргә:

тиешле муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан саклагыч корылмаларны һәм гражданнар оборонасының башка объектларын билгеләнешләре буенча файдалануга даими әзерлек хәлендә тотуны тәэмин итәргә;

гражданнар оборонасының саклагыч корылмаларын билгеләнешләре буенча файдалануга даими әзерлек хәленә китерү буенча перспектив планнарны тормышка ашыру чараларын үтәүне тикшерүдә тотарга;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Саклагыч урыннар һәм гражданнар оборонасының бүтән объектларын төзү тәртибе турында» 1999 ел, 29 ноябрь, 1309 нчы карары нигезендә халыкның билгеле бер категорияләрен яшерүне оештыру өчен муниципаль берәмлекнең гражданнар оборонасының саклагыч корылмаларына гомуми ихтыяҗны билгеләргә;

ел саен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре территориясендә гражданнар оборонасының саклагыч корылмаларын туплау, саклау һәм рациональ файдалану белән бәйле мәсьәләләрне тарайтылган утырышларда карап тикшерергә, хисап документларын Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына тапшырып;

гражданнар оборонасының саклагыч корылмаларын законсыз рәвештә исәптән төшерү һәм арендага бирү очракларын булдырмаска;

Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигать бәла-казалары нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының «Гражданнар оборонасының саклагыч корылмаларыннан файдалану кагыйдәләрен раслау һәм гамәлгә кертү турында» 2002 ел, 15 декабрь, 583 нче боерыгы нигезендә яраксыз хәлгә килгән гражданнар оборонасының саклагыч корылмаларын исәптән төшерү өчен кирәкле документларны әзерләү һәм Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигать бәла-казалары нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенә һәм Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына тапшыру эшен оештырырга.

4. Гражданнар оборонасы объектлары булган оешмалар җитәкчеләренә тәкъдим итәргә:

гражданнар оборонасы объектларын саклауны тәэмин итәргә һәм аларны билгеләнеше буенча куллануга даими әзерлек хәлендә тоту өчен чаралар күрергә;

саклагыч корылмаларны кулланганда, карап тотканда, эксплуатацияләгәндә һәм техник хәлен билгеләгәндә Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигать бәла-казалары нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының «Гражданнар оборонасының саклагыч корылмаларыннан файдалану кагыйдәләрен раслау һәм гамәлгә кертү турында» 2002 ел, 15 декабрь, 583 нче һәм «Тыныч вакытта гражданнар оборонасының саклагыч корылмаларын карап тоту һәм куллану тәртибе хакында» 2005 ел, 21 июль, 575 нче боерыклары, «Төзелеше тәмамланган саклагыч корылмаларны эксплуатациягә кабул итү һәм аларны тыныч вакытта карап тоту» СНиП 3.01.09-84, «Гражданнар оборонасының саклагыч корылмалары» СП 88.13330.2011 «СНиП II-11-77* кагыйдәләр җыелмасы таләпләре нигезендә эш итәргә.

5. Дәүләт мөлкәте белән идарә итү федераль агентлыгының Татарстан Республикасы һәм Ульяновск өлкәсе буенча төбәкара территориаль идарәсенә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Хосусыйлаштырылган предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар тарафыннан гражданнар оборонасы объектларыннан һәм мөлкәтеннән файдалану тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 1994 ел, 23 апрель, 359 нчы карары нигезендә законсыз хосусыйлаштырылган гражданнар оборонасы объектларын билгеләү һәм аларны дәүләт милкенә кире кайтару чараларын үткәрүне тәкъдим итәргә.

6. Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарына эшләргә, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына, капиталь төзелеш объектларын проектлауны, төзүне, монтажлауны һәм капиталь ремонтлауны тормышка ашыра торган барлык милек рәвешләрендәге фәнни-тикшеренү, проект, төзелеш һәм монтаж оешмалары җитәкчеләренә, куркыныч җитештерү объектлары, аеруча куркыныч, техник яктан катлаулы, уникаль объектлар, оборона һәм иминлек объектлары җитәкчеләренә Россия Федерациясенең «Гадәттән тыш хәлләрдә куркынычсызлык. Капиталь төзелеш объектларын проектлаганда гражданнар оборонасы буенча чаралар, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү буенча чаралар исемлеген эшләү тәртибе» ГОСТ Р 55201-2012 илкүләм стандартын кулланырга тәкъдим итәргә.

7. Түбәндәгеләрнең үз көчен югалтуын танырга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә гражданнар оборонасының саклагыч корылмаларын һәм бүтән объектларын төзү, карап тоту һәм куллану тәртибе турында» 2001 ел, 25 июнь, 385 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Тыныч вакытта гражданнар оборонасының саклагыч корылмаларын карап тоту тәртибе турында» 2002 ел, 2 декабрь, 681 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә гражданнар

оборонасының саклагыч корылмаларын һәм бүтән объектларын төзү, карап тоту һәм куллану тәртибе турында» 2001 ел, 25 июнь, 385 нче карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» 2004 ел, 2 август, 354 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» 2006 ел, 14 август, 409 нчы карары.

8. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\255.docx